Расланды»________
МКУ «Балтач районы башкарма комитеты мәгариф идарәсе» җитәкчесе Р.К.Мөхәрләмов

**Егетләр һәм кызлар арасында**
**“Балтач егете, Балтач кызы» — 2022” бәйгесенең**
# НИГЕЗЛӘМӘСЕ

**1. Гомуми нигезләмә.**

1.1. “Балтач егете, Балтач кызы” бәйгесе (алга таба - Бәйге) мәдәни чара булып тора.

1.2. Бәйгене оештыру, матди, техник һәм мәгълүмати эшләр өчен оештыру комитеты җаваплы.

**2. Бәйгене оештыручылар:**

2.1. «Балтач район башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе, «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» өстәмә белем бирү учреждениесе.

**3. Бәйгенең максатлары һәм бурычлары.**

3.1. “Татарлар: гамәл стратегиясе”н үтәү максатыннан, балаларда телне, татар халкының мәдәни кыйммәтен, милли үзаңны үстерү;

3.2. Татар балалары арасында сәләтле балаларны барлау;

3.3. Балалар бакчасы, мәктәп һәм гаилә арасындагы бәйләнешне ныгыту.

**4. Бәйгедә катнашу.**

4.1 Бәйгедә балалар бакчаларында тәрбияләнүчеләр катнаша ала ( 5-7 яшьлек балалар)

**5. Бәйгенең оештыру һәм үткәрү тәртибе.**

5.1 Бәйге 2022 елның 8 апрелгә кадәр уздырыла.

**6. Бәйгенең программасы.**

6.1. **<u>Беренче этап</u>**

Катнашучы видеоязмада үзе теләгән формада, иҗади рәвештә үзен һәм гаилә традицияләрен (шөгыль, һөнәр…) тәкъдим итә. Флешкадагы видеоязмалар бәйгенең оештыру комитетына **2022 елның 4 апреленнән** соңга калмыйча тапшырыла. Регламент 7 минутка кадәр. Сайлап алу туры нәтиҗәләре буенча икенче турга 20 катнашучы ( 10 малай, 10 кыз) уза.

6.2 **Йомгаклау этабы** 2022 нче елның 8 нче апрелендә «Балтач» мәдәният <u>үзәгендә үткәрелә.</u>

а) **Визитка “Әйдәгез, танышабыз!”** (5 минуттан артмаска тиеш). Бәйгедә

катнашучылар традицион яисә аерым бер стиль белән тегелгән милли киемнәр белән чыгыш ясыйлар

**б) “Татар халык йолалары”.** Халкыбызның йолалары, гореф-гадәтләре күренешләрендә катнашучылар үз осталыкларын күрсәтәләр (җыр, бию, нәфис сүз булырга мөмкин.)

в) Һәр бирем 5 балл белән бәяләнә.

**7. Бәйгенең төп номинацияләре:**

- “Балтач малае – 2022”
- “Балтач кызчыгы - 2022”

Әлеге номинацияләр бәйгенең бөтен турларын узып, иң югары балга ия булган катнашучыларга бирелә.

7.1. Оештыручылар комитеты тарафыннан өстәмә номинацияләр билгеләнә.

7.2. Номинацияләр саны финалга чыккан катнашучыларга бәйле, бер катнашучы берәр номинация буенча бүләкләнә.

7.3. Оештыру комитеты бәйгегә өстәмә номинация кертергә яисә алырга хокуклы.

**8. Бәйгежюрилары.**

8.1. Финалга чыккан катнашучыларга объектив бәя бирү өчен оештыру комитеты тарафыннан жюри билгеләнә.

8.2. Бәйгенең жюри составына фән, мәдәният, сәнгать, спорт, шулай ук сәяси һәм ижтимагый өлкәдә хезмәт итүчеләр чакырыла.

8.3. Катнашучыларга бәя бирү түбәндәге критерийлар буенча башкарыла: башкару осталыгы, җыр-моңга оста булу, пластика, сөйләм, аралашучанлык, кешегә тәэсир итү көченә ия булу, һөнәрле булу, һ.б.

8.4. Жюри ясаган нәтиҗәләр соңгы нәтиҗәләр һәм алар яңадан каралмый.

**9. Бәйгенейомгаклау**

Бәйгедә җиңүчеләргә «Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе»нең дипломнары тапшырыла.